| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РУССКО-АЗЕЛЕЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>РУС ӘҖИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2024 елның 2 феврале** Рус Әҗиле ав. **№ 1**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында»гы 2025 елның 23 гыйнварындагы 46 номерлы карары нигезендә, Рус Әҗиле авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР ИТӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегендә 2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Рус Әҗиле авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»гы 2023 елнын 31 гыйнварындагы 1 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталының Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1йорт (җирлек администрациясе бинасы), Карәшәм авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4.Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Рус Әҗиле авыл җирлеге башлыгы Г.Ф. Семахина

Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге башкарма комитетының 2025 елның 31 январендәге №1 карарына 1 нче кушымта

ТР Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегендә 2025 елнын 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4 994,68 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка ташу | 1 422,81 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 747,88 |
| **Барлыгы** | **9 165,37** |

Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге башкарма комитетының 2025 елның 31 январендәге №1 карарына 2 нче кушымта

ТР Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегендә 2025 елнын 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4994,68 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка ташу | 1422,81 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 747,87 |
| **Барлыгы** | **9 165,37** |